**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат организмында наркотик матдәләр яисә психотроп матдәләр яки потенциаль зарарлы яңа психоактив матдәләр һәм аларның метаболитлары булуга химик-токсикологик тикшеренүләрне дә кертеп, Татарстан Республикасы территориясендә медицина тикшерүе уздырырга, чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган затның әйләнә-тирәдәгеләргә куркыныч тудыра торган йогышлы авырулары булуын яисә булмавын күрсәтергә вәкаләтле медицина оешмалары исемлеген раслау турында**

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясындагы 5 нче пункты, «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый хәле турында» 2002 елның 25 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның $4^2$ статьясындагы 2 нче пункты нигезендә **карар бирәм**:

1. Чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат организмында наркотик матдәләр яисә психотроп матдәләр яки потенциаль зарарлы яңа психоактив матдәләр һәм аларның метаболитлары булуга химик-токсикологик тикшеренүләрне дә кертеп, Татарстан Республикасы территориясендә медицина тикшерүе уздырырга, чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган затның әйләнә-тирәдәгеләргә куркыныч тудыра торган йогышлы авырулары булуын яисә булмавын күрсәтергә вәкаләтле медицина оешмалары исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2026 ел, 20 август
№ 683

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2026 елның «20» августындагы
683 номерлы Указы белән
РАСЛАНДЫ

**Чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган зат организмында наркотик матдәләр яисә психотроп матдәләр яки потенциаль зарарлы яңа психоактив матдәләр һәм аларның метаболитлары булуга химик-токсикологик тикшеренүләрне дә кертеп, Татарстан Республикасы территориясендә медицина тикшерүе уздырырга, чит ил гражданы яисә гражданлыгы булмаган затның әйләнә-тирәдәгеләргә куркыныч тудыра торган йогышлы авырулары булуын яисә булмавын күрсәтергә вәкаләтле медицина оешмалары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

1. «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор А.Г. Ге исемендәге Республика клиник тире-венерология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе.
2. «Республика туберкулезны дәвалау клиник диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе.
3. «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының СПИДны һәм йогышлы авыруларны профилактикалау һәм аларга каршы көрәшү республика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе.
4. «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика наркология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе.
5. «Чит ил гражданнарына медицина тикшеренүе уздыру республика үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте.
6. «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Медицина-санитария часте.